Җәмәгать тыңлаулары үткәрү турында
Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының " Чепья авыл җирлеге » муниципаль берәмлегенең Генераль планы проекты буенча

РФ Шәһәр төзелеше кодексының 24, 28 ст. нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Советының 2007 елның 24 мартындагы 66 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында Җәмәгать тыңлауларын үткәрү турында» Нигезләмә нигезендә, кеше яшәешнең уңай шартларына, җир участокларына һәм капиталь төзелеш объектларына хокук ияләренең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү максатларында Балтач муниципаль район башлыгы КАРАР БИРӘ:

1. Чепья авыл җирлеге халкы катнашында «Чепья авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең генераль планы проекты буенча ачык тыңлаулар уздыруны билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы, Балтач районы, Чепья авылы, Ленин урамы, 12 нче йорт адресы буенча Чепья, Иске Чепья, Мельничная, Сырья, Тагашур авыллары гражданнары өчен «Чепья авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең генераль планы проектын ачык тыңлаулар уздырырга.

3. Арбор һәм Яңырчы авыллары гражданнары өчен «Чепья авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең генераль планы проектын 2019 нче елның 3нче август 10:30дан 11:00гә кадәр Арбор авылы мәдәният йортында (Татарстан Республикасы, Балтач районы, Арбор авылы, Татарстан урамы, 53/1 йорт) ачык тыңлаулар үткәрергә.

4. Балтач муниципаль районының " Чепья авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең генераль планы проектын әзерләү буенча комиссияга (алга таба - Комиссия) ачык тыңлаулар узыдырырга.

5. Комиссияга «Чепья авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге генераль планының демонстрацион материалларының күргәзмә-экспозициясен оештырырга, гавами тыңлаулар тәмамланганнан соң тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләргә.

6. Генераль план проекты буенча гражданнардан тәкъдимнәр әлеге карар басылып чыккач бер ай дәвамында Чепья авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары тарафыннан түбәндәге адрес буенча кабул ителә: Татарстан Республикасы, Балтач районы, Чепья авылы, Ленин урамы, 10нчы йорт

7. Әлеге карарны Балтач муниципаль районының рәсми сайтында baltasi.tatar.ru һәм Чепья авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Балтач муниципаль
район башлыгы Р.Р.Нутфуллин